**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

________________ ПР-283 20.12.2024 № _________

Яр Чаллы янгын сүндерү-коткару гарнизоны бүлекчәләренең Актаныш муниципаль районы территориясендә янгын сүндерү һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкару өчен чыгу расписаниесен раслау турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында»1994 елның 21 декабрендәге 69 – ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш муниципаль районы территориясендә янгын сүндерү һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкару өчен Яр Чаллы янгын сүндерү-коткару гарнизоны бүлекчәләрен оешкан төстә һәм үз вакытында җәлеп итү максатларында,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Яр Чаллы янгын сүндерү – коткару гарнизоны бүлекчәләренең Актаныш муниципаль районы территориясендә янгын сүндерү һәм авария - коткару эшләрен башкару өчен чыгу расписаниесен (алга таба – расписание) расларга.

2. Милек формаларына бәйсез рәвештә авыл җирлекләре, предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- янгын сүндерү һәм янгын сүндерү өчен җайлаштырылган техниканы чакыру урынына расписаниедә билгеләнгән тәртиптә вакытында чыгу;
- янгын сүндерү җитәкчесе таләбе буенча янгында махсус эшләр башкару өчен махсус техника, тракторлар, бульдозерлар, үзбушаткычлар бүлеп бирү;
- янгын сүндерү җитәкчесе таләбе буенча ландшафт (табигый) янгыннарын сүндерү өчен су ташу һәм җир казу техникасын бүлеп бирү;
- янгынга каршы су белән тәэмин итүнең ведомство буйсынуындагы чыганакларын (янгын сүндерү су сыйдырышлыклары һәм гидрантлары, су башнялары, су алу өчен пирслар, туңмый торган бәкеләр һ. б.) һәм аларга керү юлларын көн саен төзек хәлдә тоту;
- Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең (Актаныш муниципаль районы) 103 нче янгын сүндерү бүлеге диспетчерына көн саен 08:00 сәгатьтән 08:30 сәг кә кадәр иректе янгын сүндерү формированиеләренең хәрби әзерлеге турында белешмәләрне телефон аша тапшыру;
- янгын сүндерү машинасын ремонтка чыгарганда янгын сүндерү өчен җайлаштырылган техниканы исәпкә кую.

3. "Коммунсервис" МУП директорына янгын сүндерү районында суүткәргеч челтәрләренең максималь су бирүен, шулай ук янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганакларының төзеклеген тәэмин итү буенча барлык кичектергесез чараларны үтәүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Предприятие башлыкларына: бәхетсезлек очракларына юл куймау һәм янгыннан саклау бүлекчәләренең шәхси составы эшендә куркынычсызлык өчен шартлар тудыру максатларында, РЭЧ электр челтәренең кирәкле участокларын вакытында сүндерүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. Газ белән тәэмин ителә торган объектларда янгыннарны сүндерү урынында авария бригадаларының эшен, шулай ук, кирәк булган очракта, газ белән тәэмин итүнең тиешле участокларын сүндерүне тәэмин итүне «Әлмәтгаз» ЭҖИ РГЭХ башлыгына тәкъдим итәргә.

6. Район үзәк хастаханәсенә янгын урынында зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтүне һәм аларны дәвалау учреждениеләренә җибәрүне тәкъдим итәргә.

7. Яр Чаллы ЗЭЭУ Актаныш РУЭЧ башлыгына янгын (гадәттән тыш хәл) турында мәгълүмат җыю һәм тапшыру өчен беренче чиратта элемтә хезмәте күрсәтүне тәкъдим итәргә.

8. Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы бүлеге башлыгына зур һәм киң таралган янгыннарны сүндерү урыннарында хокук тәртибен саклау, шулай ук мөлкәтнең сакланышын тәэмин итү буенча чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

9. Яр Чаллы янгын – коткару гарнизоны башлыгы урынбасарына (Актаныш МР территориясе чикләрендә) - янгын (авария) турында хәбәр килгәндә, расписаниедә билгеләнгән тәртиптә кичекмәстән көч һәм чаралар җыюны һәм чыгуны оештырырга.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Т.Демидов